Балаларга, бигрәк авылдагыларга, олы бvләкләр алырга еш туры килми. Амир Байчуринга Мордовия Авыл хужалыгы һәм азык-толек министырлыгы Рәхмәт хаты - Благодарность тапшыра.

Амир Кадошкино районы Латышовка гомуми урта белем бирv мәктәбенен сигезенче класс укучысы. Каникулларында һәрвакыт авыл фермеры Рушан Зариф улы Поташов (КФХ) хужалыгында эшли. Ул токта азык киптерергә булыша. Ашлык әзерләv – жаваплы эш. Жинелләрдән тvгел. Яшь кенә булса да, авырлыктан курыкмый ул, оендә дә бар эштә беренчеләр рәтендә башкара. Амир, әтисе Эдуард Равил улына, техниканы тозәтергә, ә әнисе Надия Мансур кызына, ой һәм йорт эшләрен эшләргә булыша. Торле нәрсәләр белән кызыксынучан бу бала, любознательный. Авылда яшәгән Байчуриннарнын хужалыклары зур. Ә Амир булган барлык эшне башкара белә: кошларга жим сибә, кәжәләрен ашата... Житмәсә, әнисенен Мәдәният йорты хезмәтендә дә ярдәмгә килә; Амир авыл клубында vткәрелгән мәдәни чараларнын кvбесендә катнаша. Ә укуга килгәндә, ул vткән уку елын бер дvртле билгесе белән тәмамлый, калганнары гел бишлеләр. Мәктәп активисты да ул. Экология юнә-лешендәге тикшерv-эзләнv проект эше белән Амир Байчурин районда ел саен vтә торган фәнни-техник конкурста да катнаша. Менә шундый һәръяктан унган бала ул.